

Соло мецо-сопрано: Аллаһы Сөбханә вә Хак Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак Илчесе,
бөтен Галәмгә Рәхмәт итеп күндерелмеш,  Хак юлына басканнарны сөендерүче атабыз
Ибраһим галәйһиссәламнең нәселеннән булган Хак хәбибе һәм Рәсүле пәйгамбәребез
Мөхәммәт сәлаллаһы галяйһиссәламгә хәер-дога сәламнәребез, өммәтең дигән
күңелләребездән туктаусыз салават шәрифәләребез булса иде. Әмин

Хор: Әмин




Соло тенор: Җир-күкләребезне яратып, күктән сулар яудырып, елга-диңгез-дәрьяларны безнең
ихтыярга буйсындырган, Кояш-Айны без бәндәләреңә файдага биргән, кешелеккә яшәеш бүләк иткән
АллаһуТәгаләбезгә мактау-олуглауларыбыз булса иде. Әмин.

Хор: Әмин. Әмин.




Соло меццо-сопрано: Аллаһу Раббымыз барча әһле Иман вә Ислам өчен хәер бәрәкәттә
булуларын насыйб итсә иде. Әмин.

Хор: Әмин

©